РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ГЛАВА**
**ТЮЛЯЧИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Ленина ул., д. 46, с. Тюлячи, 422080
тел.: (84360) 2-11-89 (факс),
E-mail: Telache@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШЛЫГЫ**

422080, Теләче авылы, Ленин урамы, 46,
тел.: (84360) 2-11-89 (факс)
E-mail: Telache@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№ 54** **«15» июля 2015г.**

Теләче муниципаль районы Башлыгының «Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең һөнәри белемнәрен яңартуга, квалификациясен күтәрүгә һәм стажировкасын арттыруга муниципаль заказ турында» 2010 елның 13 августындагы 47 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ЗРТ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Теләче муниципаль районы Уставына таянып, Теләче районы прокурорының 2015 елның 16 июнендәге 02-08-01/595 номерлы протестын карап,

КАРАР БИРӘМ:

1. Теләче муниципаль районы Башлыгының «Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең һөнәри белемнәрен яңартуга, квалификациясен күтәрүгә һәм стажировкасын арттыруга муниципаль заказ турында» 2010 елның 13 августындагы 47 номерлы карары белән расланган «Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең һөнәри белемнәрен яңартуга, квалификациясен күтәрүгә һәм стажировкасын арттыруга муниципаль заказ турында Нигезләмәнең 1 һәм 7 пунктларныа үзгәреш кертергә, түбәндәге редакциядә бәян итеп:

1.1. «1. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, Теләче муниципаль районы Уставы, Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә, башка норматив хокукый актлар нигезендә эшләнде һәм «Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең һөнәри белемнәрен яңартуга, квалификациясен күтәрүгә һәм стажировкасын арттыруга муниципаль заказ (алга таба - муниципаль заказ) формалаштыру тәртибен билгели;

1.2. «7. Муниципаль хезмәткәрләрне һөнәри белемен яңартуга һәм квалификацияләрен күтәрү тәртибенә лицензиясе булган һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләрендә муниципаль заказ урнаштыру һәм дәүләт аккредитациясе «Дәүләт муниципаль ихтыяҗлары өчен товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру турында» 2005 елның 21 июлендәге 94-ФЗ номерлыфедераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Әлеге карар имза салынган вакыттан үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башлыгы аппараты җитәкчесе И.В. Мөбиновка йөкләргә.

ОБЩИЙ ОТДЕЛ ГОМУМИ БҮЛЕГЕ

И. Ф. Зарипов